**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «23» октябреннән №49-378

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 29 декабрендәге 17-135 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-135 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 26 маендагы 34-271 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 38-311 номерлы, 2024 елның 11 июлендәге 47-358 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. . Нигезләмәнең 4.7. статьясының 4.7.8. пунктында «66 статьяның 12 өлеше белән» сүзләрен «66 статьяның 12 һәм 12.1 өлешләре белән» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Нигезләмәнең 4.9. статьясының 4.9.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 бүлегенең 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.»

1.3. Нигезләмәнең 4.9. статьясын түбәндәге эчтәлектәге 4.9.5 пункт белән тулыландырырга:

«4.9.5. Күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләр бозылу билгеләре ачыкланса, әгәр контрольлек рәвеше турында федераль законда, Татарстан Республикасы законында шундый мөмкинлек күрсәтелгән очракта, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 өлешендәге 1 пунктында каралган тәртиптә, карар кабул ителергә мөмкин».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Экология, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов